Республика икътисады һәм энергетикасы үсешенә зур шәхси өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «Татэнергосбыт» ачык акционер җәмгыяте директоры, Казан шәһәре | Сөләйманов Рифнур Хәйдәр улын |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 10 апрель
№ ПУ-290

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 670. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә лаеклы өлеш кертүе һәм фәнни-педагогик эшчәнлектәге казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| «А.Н. Туполев исемендәге Казан милли-тикшеренү техник университеты – КАИ» югары һөнәри белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең Түбән Кама мәгълүмат технологияләре һәм телекоммуникацияләр институты (филиал) директоры | Гафиятов Илгиз Зиннәтулла улын |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 10 апрель
№ ПУ-291

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 671. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Эшендә югары күрсәткечләргә ирешүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Югары судының документлар әйләнеше һәм гражданнарны кабул итү бүлеге башлыгы | Осипова Татьяна Александровнаны |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 10 апрель
№ ПУ-292

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 672. Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга иминлексезлегә сәбәпле урнаштырылган карантинны бетерү турында

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының 3[1] статьясы нигезендә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә:

Тәтеш районының Бакырчы авылындагы Ленин урамы;

«Нива» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте Алексеевск районының Арбузов-Баран авылы янындагы атлар асрау өчен файдалана торган территориянең бер өлеше;

«Түбән Кама гравий-сортларга аеру заводы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Түбән Кама районы Түбән Афанас авылыннан төньяк-көнбатыш юнәлештә 6 километр ераклыкта урнашкан 2 гектар мәйдандагы территориясенең бер өлеше.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2013 елның 7 февралендәге ПУ-87 номерлы Указының үз көчен югалтуын танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 12 апрель
№ ПУ-296

## 673. Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларының квалификация класслары турында Вакытлыча нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон чыгару актларына Россия Федерациясе судьяларына хезмәт хакы түләүне камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон чыгару актларының (закон чыгару актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуларын тану турында» 2012 елның 25 декабрендәге ФЗ-269 номерлы Федераль законы (алга таба – Федераль закон) кабул ителү белән бәйле рәвештә һәм киләчәктә тиешле Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә кадәр **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларының квалификация класслары турында вакытлы нигезләмәне раслау хакында» 2000 елның 12 июлендәге ПУ-521 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 26 ноябрендәге ПУ-996 номерлы указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларының квалификация класслары турында Вакытлыча нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

4-9 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы Конституция суды судьялары өчен беренче, икенче һәм өченче квалификация класслары билгеләнә.

5. Квалификация класслары бирелә:

беренче квалификация классы – Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисенә;

беренче һәм икенче квалификация класслары – Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе урынбасарына;

беренче, икенче һәм өченче квалификация класслары – Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларына;

6. Квалификация классында булу срогы түбәндәгечә билгеләнә:

өченче квалификация классында – дүрт ел;

икенче квалификация классында – дүрт ел.

Беренче квалификация классында булу срогы билгеләнми.

7. Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларына квалификация класслары тиешле квалификация классы бирелү тәртибен һәм квалификация классында булу срокларын саклап, биләгән вазыйфасына туры китереп бирелә.

Квалификация классы бирелү тәртибенә һәм квалификация классында булу срогына бәйсез рәвештә:

беренче квалификация классы юридик фәннәр докторы гыйльми дәрәҗәсенә яисә профессор дигән гыйльми исемгә ия булган Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларына бирелә;

икенче квалификация классы юридик фәннәр кандидаты гыйльми дәрәҗәсенә яисә доцент дигән гыйльми исемгә, йә «Россия Федерациясенең Атказанган юристы» яисә «Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исемгә лаек булган, йә судья вазыйфасында эш стажы 10 елдан да ким булмаган Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларына бирелә.

8. Отставкага киткән Татарстан Республикасы Конституция суды судьясының, аңа бирелгән квалификация классы гомерлеккә саклана.

Татарстан Республикасының Конституция суды судьясының вәкаләтләре «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 21 статьясындагы 1 кисәкнең 6 һәм 7 пунктларында каралган нигездә туктатылганда, Татарстан Республикасы Президенты үз инициативасы белән яисә Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе тәкъдиме буенча судьяны квалификация классыннан мәхрүм итү турында карар кабул итә.

Татарстан Республикасы Конституция суды судьясының вәкаләтләре «Татарстан Республикасының Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 21 статьясындагы 1 кисәкнең 5 пунктында каралган нигездә туктатылганда, вәкаләтләре туктатылган судья квалификация классыннан мәхрүм ителә.

9. Татарстан Республикасының Конституция суды судьяларына бирелгән квалификация класслары нигезендә түбәндәге күләмдә айлык хезмәт хаклары (квалификация классы өчен хезмәт хакы) билгеләнә:

беренче квалификация классы өчен – вазыйфаи хезмәт хакының 135 проценты;

икенче квалификация классы өчен – вазыйфаи хезмәт хакының 120 проценты;

өченче квалификация классы өчен – вазыйфаи хезмәт хакының 105 проценты.».

2. Федераль закон үз көченә кергән көннән гамәлдәге Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисенә, Рәис урынбасарына, судьяларына Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларының квалификация класслары турында вакытлыча нигезләмәне раслау хакында» 2000 елның 12 июлендәге ПУ-521 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 26 ноябрендәге ПУ-996 номерлы указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларының квалификация класслары турында Вакытлыча нигезләмә (алга таба – Вакытлыча нигезләмә) буенча бирелгән квалификация класлары түбәндәге таблицада бирелгән квалификация классларына туры килә, дип билгеләргә:

| Вакытлыча нигезләмә буенча бирелгән квалификация классы | Вакытлыча нигезләмә (әлеге Указ редакциясендә) буенча билгеләнгән квалификация классы |
|---|---|
| югары квалификация классы | беренче квалификация классы |
| беренче квалификация классы | икенче квалификация классы |
| икенче квалификация классы | өченче квалификация классы |

Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе, Рәис урынбасары һәм судьялары квалификация классларын «Судьялар статусы турында» 1992 елның 26 июнендәге 3132-I номерлы Россия Федерациясе Законына (Федераль Закон редакциясендә) һәм әлеге Указга туры китерү Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе тәкъдиме буенча гамәлгә ашырыла.

3. Федераль закон үз көченә кергән көнгә отставкага киткән Татарстан Республикасы Конституция суды судьясына Вакытлыча нигезләмә буенча бирелгән квалификация классы гомерлеккә саклана.

4. Федераль закон үз көченә кергән көнгә отставкага киткән Татарстан Республикасы Конституция суды судьясына гомерлеккә билгеләнгән айлык түләү күләме тиешле вазыйфа буенча эшләүче судьяга саналырга мөмкин булган акчалата ай-

лык түләү күләменнән чыгып яңадан исәпләнергә тиеш. Бу вакытта элек бирелгән квалификация классы буенча түләүләрне яңадан исәпләү әлеге Указның 2 пунктында каралган туры килү таблицасы буенча башкарыла.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә һәм 2013 елның 1 гыйнварыннан соң барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 12 апрель
№ ПУ-297

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 674. Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында

Терлекләрнең котыру авырулы булуы ачыклану һәм аның Татарстан Республикасы торак пунктларында таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының $3^1$, 17 статьялары нигезендә **карар бирәм**:

1. Терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертергә:

а) Татарстан Республикасының түбәндәге торак пунктлары территорияләрендә:

Азнакай районының Мәлбагыш авылы;

Балтач районының Кургем авылы;

б) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Спас районының Кузнечиха авылындагы Елга аръягы урамы;

Чистай районының Изгар авылындагы Кыр урамы;

Аксубай районы Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлегенең Такталы авылыннан көньяк юнәлештә 800 метр ераклыкта урнашкан 2 гектар мәйдандагы җирләре;

Лениногорск районы Иске Писмән авылы янындагы «Иртәнге шәфәкъ» агрокомплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең машина-транспорт паркы;

Түбән Кама районындагы «Түбән Кама нефтехим» ачык акционер җәмгыяте Чишмә аучылык хуҗалыгының 62 нче кварталы.

2. Әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә карантин гамәле дәвам иткән вакытта түбәндәгеләр тыела:

йорт хайваннарын сату, аларны әлеге территориядән читкә чыгару һәм кыргый җәнлекләрне (аларны зоопаркларга чыгару өчен, башка районнарда үрчетү максатларында) тоту;

котыру авырулы яисә авыру дигән шик тудырган хайваннарны ит өчен сую;

котыру авырулы терлекләрнең сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә пасте-ризацияләнмәгән сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә дезинфекцияләнмәгән йонын, тиресен әлеге территориядән чыгару.

3. Карантин, зарури чаралар күрү шарты үтәлгәндә, терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагы көненнән ике ай вакыт узгач бетерелергә тиеш, дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә терлекләрнең котыру белән чирләвен бетерү буенча чаралар планнарын эшләргә һәм расларга, шулай ук аның гамәлгә ашырылуын тәэмин итәргә.

5. Әлеге Указның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 12 апрель
№ ПУ-298

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 675. «Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Мәдәниятне үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының һөнәри сәнгать һәм сәнгать белеме бүлеге башлыгы | Салихова Зөлфирә Якуб кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 12 апрель
№ ПУ-299

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 676. «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирү турында

Финанс-икътисад эшчәнлегендәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы хезмәткәрләре:

| | |
|---|---|
| исәп һәм хисап бүлеге башлыгы | Идрисова Резеда Фоат кызына |
| төбәк бюджетлары белән хезмәттәшлек бүлеге башлыгы урынбасары | Ханзафарова Фәридә Әсхәт кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 12 апрель
№ ПУ-300

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 677. «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирү турында

Финанс-икътисад эшчәнлегендәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе финанс-икътисад бүлегенең икътисад мәсьәләләре буенча консультанты | Гарифуллина Зөлфия Нургазиз кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 12 апрель
№ ПУ-301

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 678. «Татарстан Республикасының Атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирү турында

Театр сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры» дәүләт бюджет учреждениесе драма артисты | Вазиев Рамил Камил улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 12 апрель
№ ПУ-302

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 679. Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләреннән тыш, ауның параметрларын билгеләү турында

«Ау турында һәм аучылык ресурсларын саклау хакында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 23 статьясындагы 5 өлеше, 33 статьясындагы 1 өлешенең 4 пункты нигезендә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләреннән тыш, ауның кушымта итеп бирелүче параметрларын билгеләргә.

2. Әлеге Указның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасының Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсенә йөкләргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 12 апрель
№ ПУ-303

Татарстан Республикасы
Президентының
2013 елның 12 апрелендәге
ПУ-303 номерлы Указына
кушымта

### Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләреннән тыш, ауның параметрлары

I. Аучылык ресурсларына карата үзешчән һәм спорт авы сроклары (Россия Федерациясе Кызыл китабына һәм Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән имезүчеләр һәм кош-корт төрләреннән һәм ярдәмче төрләреннән тыш)

1.1. Тояклы хайваннарга ау сроклары:

1) кабан дуңгызы (барлык җенес-яшь төркемнәре, агымдагы елда балалаган ана дуңгызлардан һәм бер яшькә кадәрге кабан дуңгызларыннан тыш) – 1 июньнән 28 (29) февральгә кадәр;

агымдагы елда балалаган ана дуңгызлар һәм бер яшькә кадәрге кабан дуңгызлары – 1 октябрьдән 28 (29) февральгә кадәр;

2) кыр кәҗәсе:

барлык җенес-яшь төркемнәре – 1 октябрьдән 31 декабрьгә кадәр;

өлкән ана кәҗәләр куышу вакытында (Татарстан Республикасы территориясендә аучылык ресурсларын аулауның ел саен раслана торган лимитлары нигезендә) – 25 августтан 20 сентябрьгә кадәр;

3) поши:

барлык җенес-яшь төркемнәре – 1 октябрьдән 15 гыйнварга кадәр (дәвамлылыгы 90 көннән артык түгел);

өлкән ата пошилар куышу вакытында (Татарстан Республикасы территориясендә аучылык ресурсларын аулауның ел саен раслана торган лимитлары нигезендә) – 1 сентябрьдән 30 сентябрьгә кадәр.

1.2. Язгы чорда киек кошларга ау апрельнең икенче шимбәсеннән майның икенче шимбәсенә кадәр гамәлгә ашырыла.

Язгы чорның ау срогы 10 календарь көн тәшкил итә. Татарстан Республикасының аучылык биләмәләрендә язгы чорда, аучылык биләмәләренең географик урынына һәм күчмә киек кошлар миграциясе срокларына бәйле рәвештә, күп дигәндә өч срок билгеләнә. Язгы ауның алдагы сезоны сроклары хайваннар дөньясы объектларын һәм алар яшәгән мохитне саклау, федераль дәүләт күзәтчелегендә тоту һәм алардан файдалануны җайга салу буенча вәкаләтле дәүләт органы тарафыннан билгеләнә.

1.3. Киек кошларга ауның башка сроклары:

1) суда йөзүче, сазлык-болын, кыр һәм дала җәнлекләренә – августның өченче шимбәсендә 17 сәгатьтән 15 ноябрьгә кадәр;

2) казларга – 1 октябрьдән 15 ноябрьгә кадәр;

3) ау этләре, ау кошлары белән сазлык-болын җәнлекләренә – 25 июльдән 15 ноябрьгә кадәр;

4) урман җәнлекләренә – августның өченче шимбәсеннән 31 декабрьгә кадәр;

5) ау этләре, ау кошлары белән урман, кыр һәм дала җәнлекләренә – 5 августтан 31 декабрьгә кадәр.

1.4. Мехлы хайваннарга ау сроклары:

1) байбак һәм йомраннар – 1 июльдән 30 сентябрьгә кадәр;

2) бурсык – 15 августтан 31 октябрьгә кадәр;

3) сукыр тычкан – 1 июньнән 25 октябрьгә кадәр;

4) куян (ак куян, соры куян) – 15 октябрьдән 15 гыйнварга кадәр;

5) төлке, корсак, янутка охшаш эт, бүре – 15 сентябрьдән 28 (29) февральгә кадәр;

6) Америка чәшкесе, Себер көзәне, тиеннәр, селәүсен, росомаха, урман сусары, көзәннәр, ләтчә, кондыз – 1 октябрьдән 28 (29) февральгә кадәр;

7) ондатра, су тычканы – 1 октябрьдән 1 апрельгә кадәр.

## II. Кәсеп авы, фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, мәгариф эшчәнлеген тормышка ашыру максатларындагы ау, аучылык ресурслары санын җайга салу максатларындагы ау, аучылык ресурсларын акклиматизацияләү, күчерү һәм гибридлаштыру максатларындагы ау, аучылык ресурсларын ярым ирекле шартларда яисә ясалма булдырылган яшәү мохитендә тоту һәм үрчетү максатларындагы ау

Кәсеп авы, фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, мәгариф эшчәнлеген тормышка ашыру максатларындагы ау, аучылык ресурслары санын җайга салу максатларындагы ау, аучылык ресурсларын акклиматизацияләү, күчерү һәм гибридлаштыру максатларындагы ау, аучылык ресурсларын ярым ирекле шартларда яисә ясалма булдырылган яшәү мохитендә тоту һәм үрчетү максатларындагы ау гамәлдәге законнар нигезендә тормышка ашырыла.

## III. Ауны чикләүләр

3.1. 2013 – 2014 елларга түбәндәгеләргә үзешчән һәм спорт авы тыела:

кыр тавыгына, ау этләреннән һәм ау кошларыннан файдаланып аулаудан тыш;

көзге-кышкы чорда урман тавыгына;

барлык дәүләт табигать аучылык тыюлыкларында, «Кама-Ык» дәүләт табигать аучылык тыюлыгыннан тыш.

3.2.Кар капламы барлыкка килгәнче, кан тамчыларыннан эз алу буенча кыр дипломы булган ау токымлы этләрдән файдаланмыйча, тояклы кыргый хайваннарга үзешчән һәм спорт авы тыела.

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 680. «Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирү турында

Республиканың юл төзү хуҗалыгын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «Федераль юл агентлыгының Идел-Нократ төбәге автомобиль юллары федераль идарәсе» федераль казна учреждениесе башлыгы | Гатиятуллин Мөхәммәт Хәбибулла улына |

«Татарстан Республикасы Атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 12 апрель
№ ПУ-304

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 681. Татарстан Республикасы Президентының Эксперт идарәсе турында Нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты турында Нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 20 мартындагы ПУ-114 номерлы һәм «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты турында» 2006 елның 5 апрелендәге ПУ-134 номерлы указлары нигезендә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының Эксперт идарәсе турында Нигезләмәне (кушымта итеп бирелә) расларга.
2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 13 апрель
№ ПУ-305

Татарстан Республикасы
Президентының
2013 елның «13» апрелендәге
ПУ-305 номерлы Указы белән
расланды

# Татарстан Республикасы Президентының Эксперт идарәсе турында Нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Президентының Эксперт идарәсе (алга таба – Идарә) Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының Татарстан Республикасы Президенты эшчәнлеген эксперт-аналитик һәм мәгълүмати тәэмин итү максатларында төзелгән структур бүлекчәсе булып тора.

2. Идарә Татарстан Республикасы Президентына һәм Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенә буйсына.

3. Идарә эшчәнлеген үз вазыйфаи бурычлары нигезендә Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе күзәтеп тора.

4. Идарә үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Президенты указларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты турында Нигезләмәгә, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе боерыкларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

5. Идарә турында Нигезләмә Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе тәкъдиме буенча раслана.

## II. Идарәнең төп бурычлары

6. Идарәнең төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Татарстан Республикасы Президентының үз конституциячел вәкаләтләрен гамәлгә ашыруын эксперт-аналитика ягыннан тәэмин итү;

эксперт бәяләмәләре, мәгълүмати һәм аналитик докладлар, шулай ук сәнәгать, авыл хуҗалыгы, энергетика, тарифларны (бәяләрне) җайга салу, мәгълүматлаштыру һәм элемтә, төзелеш,

транспорт комплексы һәм юл хуҗалыгы, энергия ресурсларын сак тоту, урман хуҗалыгы, экология, сәламәтлек саклау, хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү, Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше, шулай ук финанс, банк, инвестиция, инновация, фәнни-техник һәм эшмәкәрлек эшчәнлеге мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенә кирәкле башка материаллар әзерләү;

Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе йөкләүләре буенча программа һәм проектлар эшләүне координацияләү, аларга экспертиза ясау.

## III. Идарәнең төп функцияләре

7. Бүлекнең төп функцияләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше программаларын эшләүдә катнашу;

Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты структур бүлекчәләре катнашында Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына еллык юлламалары өчен, шулай ук Татарстан Республикасы Президенты чыгышлары өчен материаллар җыю, анализлау һәм әзерләү;

Татарстан Республикасы Президентын эксперт бәяләмәләре, мәгълүмати-аналитик докладлар, шулай ук кирәкле башка материаллар белән тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Президенты үткәргән киңәшмәләргә һәм очрашуларга мәгълүмати-аналитик материаллар әзерләү;

уздырылган чаралар нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе йөкләмәләре проектларын әзерләү;

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы киңәшмә һәм консультатив органнар эшчәнлеген экспертлау ягыннан тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе йөкләүләре буенча Татарстан Республикасы Президенты указлары, боерыклары һәм йөкләмәләре проектларына, шулай ук Татарстан Республикасы

норматив хокукый актларына һәм аларның проектларына Идарә компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча экспертиза үткәрү;

Россия Федерациясе Президенты, Татарстан Республикасы Президенты указларын, боерыкларын һәм йөкләмәләрен, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларын һәм боерыкларын гамәлгә ашыру һәм үтәү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

Татарстан Республикасы Президенты указлары, боерыклары һәм йөкләмәләре үтәлешен тикшерүне оештыруда, Татарстан Республикасы Президенты йөкләмәләренең үтәлеше турында бәяләмәләр әзерләүдә, шулай ук Татарстан Республикасы Президентына кирәкле мәгълүматны үз вакытында бирүне тикшереп торуда катнашу;

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты структур бүлекчәләре, башкарма хакимият органнары һәм дәүләтнең башка органнары белән берлектә Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә башкарылган социаль-икътисадый тикшеренүләр исемлеген формалаштыру буенча эшне оештыруда катнашу;

Татарстан Республикасы халкының тормыш сыйфатын яхшырту буенча аналитик материаллар һәм тәкъдимнәр, сәяси, икътисадый күзәтүләр һәм башка мәгълүмат әзерләү.

Идарә шулай ук Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе йөкләүләре буенча башка функцияләрне дә тормышка ашыра.

Идарә үз функцияләрен Идарә эшчәнлеген күзәтеп торучы Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе белән хезмәттәшлектә тормышка ашыра.

## IV. Идарәнең хокуклары

8. Үз бурычларын һәм функцияләрен тормышка ашыру өчен бүлек түбәндәгеләргә хокуклы:

Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының структур бүлекчәләреннән, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратыннан, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратыннан, шулай ук Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарыннан, федераль башкарма хакимият органнарыннан, аларның территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, оешмалардан һәм вазыйфаи затлардан кирәк булган материалларны билгеләнгән тәртиптә соратырга һәм алырга;

Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының белешмәләр банкыннан файдаланырга;

аерым эшләрне башкару өчен Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары вәкилләрен җәлеп итәргә;

аерым эшләрне башкару өчен галимнәрне, экспертларны, белгечләрне, тәрҗемәчеләрне, шул исәптән Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе белән килешү буенча шартнамәчел нигездә җәлеп итәргә, проблемаларны карау, тәкъдимнәр һәм норматив хокукый актлар проектларын эшләү өчен галимнәрдән һәм белгечләрдән консультация төркемнәре, бәйсез эксперт төркемнәре булдырырга.

## V. Идарәнең хезмәттәшлек итүе

9. Үз функцияләрен гамәлгә ашыру өчен Идарә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка органнары, федераль башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, предприятиеләр һәм оешмалар, шулай ук Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының барлык структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи затлары белән, шул исәптән:

Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчеләре белән – Татарстан Республикасы Президентына аның йөкләмәләрен үтәү турында үз вакытында, тулы һәм объектив мәгълүмат бирү һәм Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше өлкәсендә тиешле мәгълүмати материаллар бирү мәсьәләләре буенча;

Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсе белән – Татарстан Республикасы Президенты указларын һәм боерыкларын әзерләү, Татарстан Республикасы шартнамәләре һәм килешүләрен әзерләү мәсьәләләре буенча, Идарә компетенциясенә кергән башка мәсьәләләр буенча;

Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт протоколы идарәсе белән – Татарстан Республикасы Президенты катнашында чаралар оештыру мәсьәләләре буенча;

Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе белән – Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлек мәсьәләләре буенча;

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаменты белән – дәүләт граждан хезмәте, кадрлар сайлау, Идарә хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм стажировкаларын оештыру мәсьәләләре буенча;

Татарстан Республикасы Президентының Матбугат хезмәте белән – Татарстан Республикасы турында материалларны массакүләм мәгълүмат чараларына бирү мәсьәләләре буенча;

Татарстан Республикасы Президентының Документлар белән тәэмин итү һәм контроль идарәсе белән – Идарәнең хезмәт язышуын үз вакытында җибәрү һәм тапшыру, Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең йөкләмәләрен үтәү һәм күрсәтелгән йөкләмәләрне контрольдән алуның максатка ярашлылыгы мәсьәләләре буенча;

Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсе белән – Идарә хезмәткәрләренең хезмәт эшчәнлеген тормышка ашыру өчен тиешле шартлар булдыру, тәрҗемә итү һәм басып чыгарыла торган материалларны җыю, иң яңа мәгълүмати технологияләр эшләү һәм кертү, канцелярия кирәк-яраклары, заманча оештыру-техник чаралар белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча.

## VI. Җаваплылык

10. Идарә хезмәткәрләре Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе раслаган вазыйфаи регламентлар нигезендә аларга йөкләнгән бурычларны үз вакытында һәм сыйфатлы үтәү өчен җаваплы булалар.

## VII. Идарә эшчәнлеген оештыру

11. Идарәнең структурасы һәм штат саны Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана.

12. Идарә эшчәнлегенә Идарә башлыгы җитәкчелек итә, ул үз вазыйфасына Татарстан Республикасы Президенты боерыгы белән Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе тәкъдиме буенча билгеләп куела һәм аннан азат ителә.

Идарә башлыгы вакытлыча эштә булмаган чорда аның вазыйфаларын Идарәнең, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе белән килештерелгән һәм, Идарә эшчәнлеген күзәтеп торучы Татарстан Республикасы Президен-

ты ярдәмчесе фикерен исәпкә алып, Идарә башлыгы тарафыннан билгеләнгән вәкаләтле вазыйфаи заты башкара.

13. Идарә хезмәткәрләре үз вазыйфаларына Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе тарафыннан Идарә башлыгы тәкъдиме буенча билгеләп куела һәм азат ителә.

14. Идарә эшчәнлеген мәгълүмати, документлар белән, матди-техник, транспорт белән тәэмин итүне, шулай ук хезмәткәрләргә матди-техник һәм социаль-көнкүреш хезмәте күрсәтүне Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсе башкара.

15. Идарәнең хезмәт язышып торуын алып бару өчен гербле бланкы була.

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 682. «Татарстан Республикасының Атказанган газ тармагы хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Республиканың газ сәнәгате үсешенә өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «Газпром межрегионгаз Казань» ябык акционер җәмгыяте генераль директоры | Ханбиков Ринат Сәгыйть улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган газ тармагы хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 13 апрель
№ ПУ-306

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 683. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Эчке эшләр органнарына югары квалификацияле белгечләр әзерләүдәге казанышлары һәм хезмәт эшчәнлегендә югары күрсәткечләргә ирешүе өчен

| | |
|---|---|
| «Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан юридик институты» югары һөнәри белем бирү федераль дәүләт казна мәгариф учреждениесе башлыгының һөнәри хезмәт һәм физик әзерлек буенча урынбасары | Синников Владимир Борисовичны |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 13 апрель
№ ПУ-307

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 684. «Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Мәдәниятне үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Балалар иҗат үзәге» балаларга өстәмә белем бирү муниципаль бюджет мәктәптән тыш уку учреждениесенең өстәмә белем бирү педагогы | Шәрәфиева Ирина Альберт кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 13 апрель
№ ПУ-308

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 685. «Татарстан Республикасының Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Халык сәламәтлеген саклау эшендәге казанышлары һәм намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының махсус программалар эшләү һәм гамәлгә кертү бүлеге әйдәүче консультанты | Мәрданова Эльза Фрид кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 13 апрель
№ ПУ-309

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 686. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Республиканың дәүләти үсеше өлкәсендәге югары казанышлары, күпьеллык нәтиҗәлехезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Оештыру идарәсе башлыгы урынбасары | Фәррахиева Диләрә Илгиз кызын |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 13 апрель
№ ПУ-310

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 687. «Татарстан Республикасының Атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем бирү турында

Мәгариф өлкәсендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы урынбасары | Афонская Валентина Александровнага |

«Татарстан Республикасының Атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 13 апрель
№ ПУ-311

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 688. «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирү турында

Финанс-икътисад эшчәнлегендәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты» муниципаль казна учреждениесенең хисап, контроль һәм финанс тәэминаты бүлеге баш белгече | Малышева Ксения Петровнага |

«Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 13 апрель
№ ПУ-312

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 689. «Татарстан Республикасының Атказанган химигы» дигән мактаулы исем бирү турында

Нефть химиясе сәнәгатен үстерүгә өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «Түбән Кама нефтехим» ачык акционер җәмгыятенең синтетик каучук җитештерү заводы директоры | Әмирханов Әхтәм Талип улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган химигы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 16 апрель
№ ПУ-313

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 690. «Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирү турында

Законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклаудагы казанышлары, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Мамадыш районы прокуроры урынбасары | Корчагина Әлфия Хәлим кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 17 апрель
№ ПУ-314

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 691. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Финанс-икътисад эшчәнлегендәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты директоры урынбасары | Вәлиев Ринат Равил улын |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 17 апрель
№ ПУ-315

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 692. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Илебездә машина төзү тармагын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «КАМАЗ» ачык акционер җәмгыяте генераль директорының сату һәм сервис буенча урынбасары | Пронин Евгений Павловичны |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 17 апрель
№ ПУ-316

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 693. «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены белән бүләкләү турында

Яшьләргә хәрби-патриотик тәрбия бирүгә лаеклы өлеш кертүе, актив иҗтимагый эшчәнлеге һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасының Сугыш һәм хәрби хезмәт ветераннары (инвалидлары) иҗтимагый оешмасы рәисе | Юлашев Әхәт Гайнулла улын |

«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 17 апрель
№ ПУ-317

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 694. Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләү турында

Күп бала табып, аларны намус белән тәрбияләгән ишле бала аналарын Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләргә:

Аксубай муниципаль районы буенча

| | |
|---|---|
| Иске Үзи авылыннан биш бала анасы | Артамонова Татьяна Викторовнаны |
| Иске Мукшы авылыннан биш бала анасы | Иванова Надежда Николаевнаны |

Чистай муниципаль районы буенча

| | |
|---|---|
| Чистай шәһәреннән биш бала анасы | Дьяконова Наталья Викторовнаны |

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 17 апрель
№ ПУ-318

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 695. «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале белән бүләкләү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре, җирле үзидарәне үстерүгә лаеклы өлеш кертүләре өчен:

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы | Владимиров Олег Ивановичны |
| Татарстан Республикасы Балык Бистәсе районының «Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы | Гатиятов Харис Хафиз улын |

«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 17 апрель
№ ПУ-319

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 696. «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале белән бүләкләү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, җирле үзидарәне булдыруга һәм үстерүгә лаеклы өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Актаныш авыл башкарма комитеты җитәкчесе | Әмирханов Мөнир Мәснәви улын |

«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 17 апрель
№ ПУ-320

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 697. «Татарстан Республикасының Атказанган машина төзүчесе» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм очкычлар төзү тармагын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

«Заречье» ябык акционер җәмгыяте генераль директоры, Казан шәһәре — Локай Леонид Викторовичка

«Татарстан Республикасының Атказанган машина төзүчесе» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 19 апрель
№ ПУ-321

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 698. «Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан» медале белән бүләкләү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм Татарстан Республикасының нефть сәнәгатен үстерүгә лаеклы өлеш кертүе өчен

«ТМС групп» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте ТМС Бизнес Сервис идарә компаниясенең проект офисы әйдәүче инженеры, Әлмәт шәһәре — Гущин Михаил Викторовичны

«Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 19 апрель
№ ПУ-322

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 699. «Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан» медале белән бүләкләү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм Татарстан Республикасының нефть сәнәгатен үстерүгә лаеклы өлеш кертүе өчен

нефть сәнәгате ветераны — Шәмсетдинов Марс Гарәфи улын

«Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 19 апрель
№ ПУ-323

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 700. «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирү турында

Социаль-икътисадый эшчәнлектәге казанышлары һәм нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «Генерацияләүче компания» ачык акционер җәмгыяте баш бухгалтеры – бухгалтерлык исәбе һәм салым салу идарәсе башлыгы, Казан шәһәре | Сафина Рауза Тимер кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 19 апрель
№ ПУ-325

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 701. «Татарстан Республикасының Атказанган коткаручысы» дигән мактаулы исем бирү турында

Аварияләр, һәлакәтләр һәм табигать бәла-казаларын кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерүдәге казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| «Татарстан Республикасы Гражданоборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге буенча идарәсе» Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесе башлыгы | Зыятдинов Рафаил Хафиз улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган коткаручысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 19 апрель
№ ПУ-326

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 702. «Татарстан Республикасының Атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирү турында

Театр сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «Чаллы дәүләт татар драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе драма артисты | Гыйләҗев Равил Рәшит улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел,19 апрель
№ ПУ-327

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 703. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында» Татарстан Республикасы Президенты Указына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»Татарстан Республикасы Законы, Рос-

сия Федерациясе Президентының «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2013 елның 2 апрелендәге 309 номерлы һәм «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору хакында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2013 елның 2 апрелендәге 310 номерлы указлары нигезендә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында» 2009 елның 30 декабрендәге 702 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 1 ноябрендәге 711 номерлы һәм 2012 елның 16 маендагы 343 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) атаманы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында»;

б) преамбулада «20 статьясы» сүзләрен «20 һәм $20^1$» сүзләренә, «17 статьясы» сүзләрен «17 һәм $17^1$ статьялары» сүзләренә алмаштырырга;

в) 1 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында нигезләмә (1 нче кушымта);»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәре чыгымнары турында, аның хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балалары чыгымнары турында белешмә формасы (6 нчы кушымта).»;

г) 1 нче кушымтаны, әлеге Указга 1 нче кушымтага туры китереп, яңа редакциядә бәян итәргә;

д) әлеге Указга 2 нче кушымта нигезендә 6 нчы кушымта өстәргә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары (муниципаль органнар) җитәкчеләренә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге 702 номерлы Указына 4 нче һәм 5 нче кушымталарда бирелгән формалар буенча белешмәләрнең тиешле бүлекләрен тутырганда Россия Федерациясе Президентының «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2013 елның 2 апрелендәге 309 номерлы Указының 7 пункты һәм 28 пунктының «б» пунктчасында билгеләнгән таләпләрнең үтәлүен тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаментына Россия Федерациясе Президентының «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2013 елның 2 апрелендәге 309 номерлы Указының 26 пунктының «б» һәм «в» пунктчаларында билгеләнгән йөкләмәләрнең үтәлүен тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына үз вәкаләтләре чикләрендә «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законы гамәлгә ашыру буенча тиешле чаралар күрүне тәкъдим итәргә.

5. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 22 апрель
№ ПУ-328

Татарстан Республикасы
Президентының
2013 елның 22 апрелендәге
ПУ-328 номерлы Указына
1 нче кушымта

«Татарстан Республикасы
Президентының
2009 елның 30 декабрендәге
ПУ-702 номерлы Указына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында**

## НИГЕЗЛӘМӘ

1. Элеге Нигезләмә белән түбәндәгеләрне бирү тәртибе билгеләнә:

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын (алга таба шулай ук – граждан хезмәте вазыйфаларын) биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре турында, милек хокукындагы мөлкәтләре, мөлкәти характердагы йөкләмәләре (алга таба – керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр) хакындагы белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, милек хокукында аларныкы булган мөлкәт хакында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү;

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук үзенең чыгымнары һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр (алга таба – керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр) бирү.

2. Әгәр граждан биләүне дәгъвалаган яисә граждан хезмәткәре биләгән Татарстан Республикасы граждан хезмәте вазыйфасы Татарстан Республикасы Президенты тарафын-

нан билгеләнә торган тиешле граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә (алга таба – Вазыйфалар исемлегенә) керсә, граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданга (алга таба – граждан) керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә (алга таба – граждан хезмәткәре) керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү бурычы йөкләнә.

3. Керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр гражданнар тарафыннан, алар Вазыйфалар исемлегендә каралган граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләнгәндә, расланган белешмәләр формаларында бирелә.

4. Керемнәр, чыгымнар турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр Вазыйфалар исемлегендә каралган граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче гражданнар тарафыннан расланган белешмәләр формаларында ел саен хисап елыннан соң килгән елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча бирелә.

5. Граждан хезмәте вазыйфасына билгеләп куелганда граждан түбәндәгеләрне бирә:

а) граждан хезмәте вазыйфасын дәгъвалау өчен документлар бирү елыннан алдагы календарь ел өчен барлык чыганаклардан (элеккеге эш урыны буенча яисә сайланган вазыйфаны биләү урыны буенча алынган керемнәрне, пенсияне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) үз керемнәре турында белешмәләр, шулай ук милек хокукында аныкы булган мөлкәт хакында белешмәләр һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләү өчен документлар биргән айдан алдагы айның беренче числосына (хисап вакытына) торышы буенча мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;

б) граждан хезмәтен биләү өчен граждан тарафыннан документлар бирелгән елдан алдагы календарь ел өчен аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының барлык чыганаклардан (эш хакын, пенсияне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) алган керемнәре турында белешмәләр, шулай ук милек хокукында аларныкы булган мөлкәтләре хакында белешмәләр һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләү өчен документлар биргән айдан алдагы айның беренче числосына (хисап вакытына) торышы буенча мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр.

6. Граждан хезмәткәре ел саен түбәндәгеләрне бирә:

а) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) барлык чыганаклардан (акчалата түләүне, пенсияне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) үзенең керемнәре турында белешмәләр, шулай ук милек хокукында аныкы булган мөлкәт хакында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында хисап чорының ахырына булган торышына белешмәләр;

б) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) барлык чыганаклардан (акчалата түләүне, пенсияне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында белешмәләр, шулай ук милек хокукында аларныкы булган мөлкәт хакында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында хисап чорының ахырына булган торышына белешмәләр;

в) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлешләре, пайлар) сатып алу буенча һәрбер килешү буенча хисап чорындагы (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәрге) үз чыгымнары турында, шулай ук үзенең хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балалары чыгымнары турында, әгәр килешү суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) килешү төзелгәнчегә кадәр булган соңгы өч еллык гомуми кеременнән артып китсә, һәм алар хисабына килешү башкарылган керемнәр чыганаклары турында белешмәләр.

7. Вазыйфалар исемлегенә кертелмәгән граждан хезмәте вазыйфасын биләүче граждан хезмәткәре һәм бу Вазыйфалар исемлегенә кертелгән граждан хезмәте вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакындагы белешмәләрне әлеге Нигезләмәнең 2, 3 һәм 5 пунктлары нигезендә бирә.

8. Әлеге Нигезләмәнең 5 һәм 6 пунктларында каралган белешмәләр Татарстан Республикасы дәүләт органы җитәкчесе (дәүләт вазыйфасын биләүче зат) исеменә Татарстан Республикасы дәүләт органының дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча бүлекчәсенә (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт органының кадрлар хезмәте) бирелә.

Билгеләнүен һәм аңардан азат ителүен Татарстан Республикасы Президенты башкарган граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъва итүче гражданнар тарафыннан бирелә торган аларның керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакындагы белешмәләр, шулай ук күрсәтелгән граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче граждан хезмәткәрләре керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти харак-

тердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр Татарстан Республикасы дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаментына җибәрелә.

Билгеләнүен һәм аңардан азат ителүен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты башкарган граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъва итүче гражданнар тарафыннан бирелә торган аларның керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакындагы белешмәләр, шулай ук күрсәтелгән граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче граждан хезмәткәрләре керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр Татарстан Республикасы дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча бүлекчәсенә җибәрелә.

9. Граждан яисә граждан хезмәткәре керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакындагы үзләре биргән белешмәләрдә нинди дә булса мәгълүматлар чагылдырылмаган яисә тулысынча чагылдырылмаган яки хаталар булуын ачыклаган очракта, әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә алар анықланган белешмәләр бирергә хокуклы.

Граждан хезмәткәре әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында күрсәтелгән вакыт узганнан соң өч ай дәвамында анықланган белешмәләр бирергә мөмкин.

10. Граждан хезмәткәре объектив сәбәпләр аркасында хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирмәгән очракта, әлеге факт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтларын җайга салу буенча тиешле комиссия тарафыннан каралырга тиеш.

11. Әлеге Нигезләмә нигезендә граждан һәм граждан хезмәткәре тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында бирелгән белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү законнар нигезендә тормышка ашырыла.

12. Әлеге Нигезләмә нигезендә граждан һәм граждан хезмәткәре тарафыннан бирелгән белешмәләр, әгәр дә федераль закон белән алар дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматларга кертелмәсә, конфиденциаль характердагы белешмәләр булып тора.

Әлеге белешмәләр Татарстан Республикасы дәүләт органы җитәкчесенә (дәүләт вазыйфасын биләүче затка) һәм Татарстан Республикасы дәүләт органының граждан хезмәткәрләрен вазыйфага билгеләү һәм вазыйфасыннан азат итү вәкаләтләре бирелгән башка урындагы затларга, шулай ук федераль законнарда каралган очракларда урындагы башка затларга бирелә.

13. Граждан хезмәткәренең, аның хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турындагы, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакындагы белешмәләр, шулай ук җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлешләре, пайлар) сатып алу буенча чыгымнары турында белешмәләр, әгәр килешү суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) килешү төзелгәнгә кадәр булган соңгы өч еллык гомуми кеременнән артып китсә, алар хисабына килешү башкарылган керемнәр чыганаклары турында белешмәләр Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасының тиешле дәүләт органы рәсми сайтында урнаштырыла, ә әлеге белешмәләр тиешле дәүләт органының рәсми сайтында булмаган очракта – массакүләм мәгълүмат чаралары соравы буенча аларда бастырып чыгару өчен бирелә.

14. Вазыйфаи бурычларына әлеге Нигезләмә буенча граждан һәм граждан хезмәткәре тарафыннан бирелә торган белешмәләр белән эшләү кергән, аларны таратуда яисә Россия Федерациясе законнарында каралмаган максатларда файдалануда гаепле дәүләт граждан хезмәткәрләре Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.

15. Граждан һәм әлеге Нигезләмәнең 7 пунктында күрсәтелгән граждан хезмәткәре тарафыннан керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында әлеге Нигезләмә буенча бирелгән белешмәләр, граждан хезмәте вазыйфасына билгеләп куелганда, шулай ук граждан хезмәткәре тарафыннан ел саен бирелүче белешмә һәм әлеге белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның шәхси эшенә теркәлә.

Граждан яисә әлеге Нигезләмәнең 7 пунктында күрсәтелгән граждан хезмәткәре үзләренең керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмә биргән

граждан хезмәткәре Вазыйфалар исемлегенә кертелгән вазыйфага билгеләп куелмаган очракта, бу белешмәләр аларның язмача гаризасы буенча башка документлар белән бергә кире кайтарып бирелә.

16. Граждан үзенең керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирмәгән яисә күрә торып ялган белешмәләр биргән очракта, граждан хезмәте вазыйфасына билгеләнә алмый, ә граждан хезмәткәре граждан хезмәткәре вазыйфасыннан азат ителә яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә башка төр дисциплинар җаваплылыкка тартыла.

Граждан хезмәткәрләре үз чыгымнары турында белешмәләр бирмәсә, яисә тулы булмаган йә дөрес булмаган белешмәләр бирсә яки үз хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балалары чыгымнары турында белешмәләр бирмәсә яисә күрәләтә тулы булмаган яки дөрес булмаган белешмәләр бирсә, әгәр мондый белешмәләр бирү мәҗбүри булса, бу аларны биләгән вазыйфаларыннан азат итүгә, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтеннән билгеләнгән тәртиптә чыгаруга китерәчәк хокук бозу булып тора.».

Татарстан Республикасы
Президентының
2013 елның 22 апрелендәге
ПУ-328 номерлы Указына
2 нче кушымта

«Татарстан Республикасы
Президентының
2009 елның 30 декабрендәге
ПУ-702 номерлы Указына
6 нчы кушымта

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәре чыгымнары турында, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары хакында
БЕЛЕШМӘ[1]

______________________________________
(дәүләт органы җитәкчесе
______________________________________
[дәүләт вазыйфасын биләүче
______________________________________
зат] вазыйфасы, Ф.И.А. ис.)

Мин,____________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу вакыты)
_____________________________________________________________
____________________________________________________________,
(хезмәт итү урыны, биләгән вазыйфасы)

түбәндәге адрес буенча яшәүче: ___________________________
(яшәү һәм (яисә) теркәлү урыны адресы)
_____________________________________________________________
____________________________________________________________,

20__ елның 1 гыйнварыннан 20__ елның 31 декабренә кадәрге хисап чорында ____________________________________________
_________________________________________________________
(минем тарафтан, хатыным (ирем), балигъ булмаган балам тарафыннан[2])
____________________________________________________________,
____________________________________________________________,
_____________________________________________________________

_____________________________________________________________
(җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты,
_____________________________________________________________
транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмалар устав (җыелма)
_____________________________________________________________
капиталындагы катнашу өлеше, пайлар)
_____________________________________________________________
_____________________________________________________________
(сату-сатып алу килешүе яисә законда каралган
_____________________________________________________________
милек сатып алуның башка нигезе[3])
__________________________________ нигезендә сатып алынды.

Килешү суммасы ________________________________ сум.
Мөлкәт сатып алынган акчаны табу чыганагы булып түбәндәгеләр тора[4]:

______________________________________________________

______________________________________________________

Әлеге белешмәне бирүче Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең һәм аның хатынының (иренең) мөлкәтне сатып алганчы соңгы өч елда уртак керемнәре суммасы ____________

______________________________________________________

_________________________________________________ сум.

Әлеге белешмәнең дөреслеген һәм тулылыгын раслыйм.
«___» _________________ 20___ ел

______________________________________________________
(белешмәне бирүче Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең имзасы)

Белешмәне ____________________________________________
(белешмәне кабул иткән затның Ф.И.А. ис. һәм имзасы)
________________________________________________ кабул итте.

---

[1] Белешмә, әгәр килешү суммасы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең һәм аның хатынының (иренең) килешү төзегәнче соңгы өч елдагы уртак керемнәреннән артык булса, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә белән бергә бирелә.

[2] Әгәр килешү хатыны (ире) һәм (яисә) балигъ булмаган баласы тарафыннан төзелгән булса, тиешенчә хатыны (ире) һәм (яисә) балигъ булмаган баласының фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу вакыты, тору һәм (яисә) теркәлү урыны күрсәтелә.

[3] Белешмәгә милек хокукы алу турында шартнамәнең яисә башка документның күчермәсе теркәп бирелә.

[4] Белешмәне бирүче Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең һәм аның хатынының (иренең) төп эш урыны буенча кереме (хатынының (иренең) фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу вакыты, тору һәм (яисә) теркәлү урыны күрсәтелә); күрсәтелгән затларның закон белән рөхсәт ителгән башка эшчәнлегеннән кереме; банклардагы һәм башка кредит оешмаларындагы кертемнәрдән керем, алдагы елларда җыелган акча; мирас; бүләк; заем; ипотека; мөлкәт сатудан керем; башка кредит йөкләмәләре; башкалар.».

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 704. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз чыгымнары турында, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары хакында мәгълүмат бирергә бурычлы вазыйфалары исемлеген раслау турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль законның 20[1] статьясы һәм «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 17[1] статьясы нигезендә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз чыгымнары турында, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары хакында мәгълүмат бирергә бурычлы вазыйфалары исемлеген расларга (кушымтада бирелә).

2. Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгәндә муниципаль хезмәткәрләр үз чыгымнары турында, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары хакында мәгълүмат бирергә бурычлы вазыйфалары исемлеген эшләгәндә һәм раслаганда әлеге Указ нигезләмәләрен исәпкә алуны тәкъдим итәргә.

3. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 22 апрель
№ ПУ-329

Татарстан Республикасы
Президентының
2013 елның 22 апрелендәге
ПУ-329 номерлы
Указы белән расланды

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз чыгымнары турында, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары хакында мәгълүмат бирергә бурычлы вазыйфалары
исемлеге

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең гражданнар вазыйфага билгеләнгәндә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре вазыйфа биләгәндә үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә бурычлы вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-701 номерлы Указы белән расланган исемлекнең 1 пунктына кертелгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең гражданнар вазыйфага билгеләнгәндә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре вазыйфа биләгәндә үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында мәгълүмат бирергә бурычлы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары (алга таба – Вазыйфалар исемлеге).

2. Исемлекнең 2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт органнары җитәкчеләре тарафыннан расланган, Татарстан Республикасы дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә кертелгән вазыйфага билгеләнгәндә һәм аларны биләгәндә үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында мәгълүмат бирергә бурычлы вазыйфалары исемлегенә кертелгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары.

**705. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Президентының «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2013 елның 2 апрелендәге 309 номерлы һәм «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2013 елның 2 апрелендәге 310 номерлы указлары нигезендә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында» 2010 елның 11 гыйнварындагы ПУ-4 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 16 маендагы ПУ-343 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәреше белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында»;

б) 1 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында нигезләмә (1 нче кушымта);»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның чыгымнары турында, аның хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары хакында белешмә формасын (6 нчы кушымта).»;

в) 1 нче кушымтаны әлеге Указның 1 нче кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

г) әлеге Указның 2 нче кушымтасы нигезендә 6 нчы кушымта өстәргә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларга, керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр тутырганда һәм законнарда билгеләнгән тәртиптә керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрне тапшырганда Россия Федерациясе Президентының «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2013 елны 2 апрелендәге 309 номерлы Указының 7 пункты һәм 28 пунктның «б» пунктчасы белән билгеләнгән таләпләрне үтәүне тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларга карата «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» Федераль законны гамәлгә ашыру буенча үз компетенцияләре чикләрендә кирәкле чаралар күрергә тәкъдим итәргә.

4. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 22 апрель
№ ПУ-330

Татарстан Республикасы
Президентының
2013 елның 22 апрелендәге
ПУ-330 номерлы Указына
1 нче кушымта

«Татарстан Республикасы
Президентының
2010 елның 11 гыйнварындагы
ПУ-4 номерлы Указына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында Нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә белән түбәндәгеләрне бирү тәртибе билгеләнә:

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан алган керемнәре турында, милек хокукындагы мөлкәтләре, мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, милек хокукында аларныкы булган мөлкәт хакында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр (алга таба – керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр);

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр, шулай ук үзенең чыгымнары һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында мәгълүмат (алга таба – керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр).

2. Әлеге Нигезләмә нигезендә керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләрне тиешенчә Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, шулай ук законнар белән күрсәтелгән белешмәләрне бирүнең башка тәртибе һәм рәвеше билгеләнмәгән

булса, керемнәр, чыгымнар турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләрне Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар бирә.

3. Керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан вазыйфага билгеләп куелганда (сайланганда, расланганда) расланган формалар буенча бирелә;

4. Керемнәр, чыгымнар турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан ел саен, хисап елыннан соңгы елның 30 апреленнән соңга калмыйча бирелә.

5. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы граждан вазыйфага билгеләп куелганда (сайланганда, расланганда) түбәндәгеләрне бирә:

а) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын дәгъвалау өчен документлар бирү елыннан алдагы календарь ел өчен барлык чыганаклардан (элеккеге эш урыны буенча яисә сайланган вазыйфаны биләү урыны буенча алынган керемнәрне, пенсияне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) үз керемнәре турында белешмәләр, шулай ук милек хокукында аныкы булган мөлкәт хакында белешмәләр һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләү өчен документлар биргән айдан алдагы айның беренче числосына (хисап вакытына) торышы буенча мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;

б) хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын дәгъвалау өчен гражданның документлар бирү елыннан алдагы календарь ел өчен барлык чыганаклардан (эш хакын, пенсияне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) алган керемнәре турында белешмәләр, шулай ук милек хокукында аларныкы булган мөлкәтләре хакында белешмәләр һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләү өчен документлар биргән айдан алдагы айның беренче числосына (хисап вакытына) торышы буенча мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр.

6. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат ел саен түбәндәгеләрне бирә:

а) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) барлык чыганаклардан (акчалата түләүне, пенсияне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) үзенең керемнәре турында белешмәләр, шулай ук милек хокукында аныкы булган мөлкәт хакында һәм

мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында хисап чорының ахырына булган хәлдәге белешмәләр;

б) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) барлык чыганаклардан (акчалата түләүне, пенсияне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында белешмәләр, шулай ук милек хокукында аларныкы булган мөлкәт хакында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында хисап чорының ахырына булган торышына белешмәләр;

в) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр), әгәр килешү суммасы Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның һәм аның иренең (хатынының) килешү алдыннан соңгы өч елындагы гомуми кеременнән артык булса, җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталында катнашу өлеше, пайлары) сатып алу турында һәр килешү буенча үзенең чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары һәм алар исәбенә башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр.

7. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъва итүче гражданнар, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар әлеге Нигезләмәнең 5 һәм 6 пунктларында каралган белешмәләрне Татарстан Республикасы Президенты исеменә Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаментына бирәләр.

8. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы граждан яисә Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакындагы үзләре биргән белешмәләрдә нинди дә булса мәгълүматлар чагылдырылмаган яисә тулысынча чагылдырылмаган яки хаталар булуын ачыклаган очракта, алар әлеге Нигезләмә билгеләгән тәртиптә аныкланган белешмәләр бирергә хокуклы.

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында күрсәтелгән вакыт узганнан соң өч ай дәвамында аныкланган белешмәләрне бирә ала.

9. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат объектив сәбәпләр аркасында хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирмәгән очракта, әлеге факт Татарстан Республикасы Президенты төзегән тиешле комиссия тарафыннан каралырга тиеш.

10. Әлеге Нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан бирелгән белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү законнар нигезендә тормышка ашырыла.

11. Әлеге Нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан бирелгән белешмәләр, әгәр дә федераль закон белән алар дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматларга кертелмәсә, конфиденциаль характердагы белешмәләр булып тора.

Әлеге белешмәләр Татарстан Республикасы Президентына һәм компетенцияләренә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларына билгеләү (сайлау, раслау) кергән Татарстан Республикасы дәүләт органнарына, шулай ук федераль законнарда каралган очракларда урындагы башка затларга бирелә ала.

12. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турындагы, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакындагы белешмәләр, шулай ук, әгәр килешү суммасы Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) килешү алдыннан соңгы өч елындагы гомуми кеременнән артык булса, җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталында катнашу өлеше, пайлары) сатып алу буенча килешү төзү алар исәбенә башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр, гамәлдәге законнарда каралган тәртиптә Татарстан Республикасының тиешле дәүләт органы рәсми сайтында урнаштырыла, ә әлеге белешмә тиешле дәүләт органының рәсми сайтында булмаган очракта – массакүләм мәгълүмат чаралары соравы буенча аларда бастырып чыгару өчен бирелә.

13. Вазыйфаи бурычларына әлеге Нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар биргән белешмәләр белән эшләү кергән, аларны таратуда яисә Россия Федерациясе законнарында каралмаган максатларда файдалануда гаепле Татарстан Республикасы дәүләт

граждан хезмәткәрләре Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.

14. Әлеге Нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат тарафыннан бирелгән керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакындагы белешмәләр, вазыйфага билгеләп куелганда (сайланганда, расланганда), шулай ук аның тарафыннан ел саен бирелүче керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр һәм әлеге белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның шәхси эшенә теркәлә.

Әлеге Нигезләмә нигезендә үзенең керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмә биргән граждан Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасына билгеләп куелмаган (сайланмаган, расланмаган) очракта, бу белешмә аның язмача гаризасы буенча башка документлар белән бергә кире кайтарып бирелә.

15. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы граждан һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирмәгән яисә күрә торып ялган белешмәләр биргән очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат тарафыннан үзенең чыгымнары турында белешмәләр бирмәү яисә аларны тулы булмаган килеш бирү яисә ялган белешмәләр бирү йә үз хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балалары чыгымнары турында белешмәләр бирмәү яисә күрә торып тулы булмаган яисә ялган белешмәләр бирү, әгәр мондый белешмәләр бирү мәҗбүри булса, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә аны биләгән вазыйфасыннан азат итүгә китерүче хокук бозу булып тора.».

Татарстан Республикасы
Президентының
2013 елның 22 апрелендәге
ПУ-330 номерлы Указына
2 нче кушымта

«Татарстан Республикасы
Президентының
2010 елның 11 гыйнварындагы
ПУ-4 номерлы Указына
6 нчы кушымта

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат чыгымнары турында, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары хакында
БЕЛЕШМӘ[1]

Татарстан Республикасы
Президентына
______________________

Мин,_____________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу вакыты)
____________________________________________________________
___________________________________________________________,
(хезмәт итү урыны, биләгән вазыйфасы)

түбәндәге адрес буенча яшәүче: ____________________________
(яшәү һәм (яисә) теркәлү урыны адресы)
____________________________________________________________
___________________________________________________________,

20__ елның 1 гыйнварыннан 20__ елның 31 декабренә кадәрге хисап чорында ______________________________________________
____________________________________________________________
(минем тарафтан, хатыным (ирем), балигъ булмаган балам тарафыннан[2])
___________________________________________________________,
___________________________________________________________,
____________________________________________________________

____________________________________________________________
(җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты,
____________________________________________________________
транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмалар устав (җыелма)
____________________________________________________________
капиталындагы катнашу өлеше, пайлар)
____________________________________________________________
____________________________________________________________
(сату-сатып алу килешүе яисә законда каралган
____________________________________________________________
милек сатып алуның башка нигезе[3])
___________________________________ нигезендә сатып алынды.

Килешү суммасы ________________________________ сум.
Мөлкәт сатып алынган акчаны табу чыганагы булып түбәндәгеләр тора[4]:
___________________________________________________
__________________________________________________

Әлеге белешмәне бирүче Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең һәм аның хатынының (иренең) мөлкәтне сатып алганчы соңгы өч елда уртак керемнәре суммасы ____________
___________________________________________________
_______________________________________________ сум.

Әлеге белешмәнең дөреслеген һәм тулылыгын раслыйм.
«___» _______________ 20___ ел
___________________________________________________
(белешмәне бирүче Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең имзасы)

Белешмәне ________________________________________
(белешмәне кабул иткән затның Ф.И.А. ис. һәм имзасы)
______________________________________________ кабул итте.

---

1 Белешмә, әгәр килешү суммасы Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) килешү төзегәнче соңгы өч елдагы уртак керемнәреннән артык булса, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә белән бергә бирелә.

2 Әгәр килешү хатыны (ире) һәм (яисә) балигъ булмаган баласы тарафыннан төзелгән булса, тиешенчә хатыны (ире) һәм (яисә) балигъ булмаган баласының фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу вакыты, тору һәм (яисә) теркәлү урыны күрсәтелә.

3 Белешмәгә милек хокукы алу турында шартнамәнең яисә башка документның күчермәсе теркәп бирелә.

4 Белешмәне бирүче Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) төп эш урыны буенча кереме (хатынының (иренең) фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу вакыты, тору һәм (яисә) теркәлү урыны күрсәтелә); күрсәтелгән затларның закон белән рөхсәт ителгән башка эшчәнлегеннән кереме; банклардагы һәм башка кредит оешмаларындагы кертемнәрдән керем, алдагы елларда җыелган акча; мирас; бүләк; заем; ипотека; мөлкәт сатудан керем; башка кредит йөкләмәләре; башкалар.».

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 706. «Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирү турында

Законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы казанышлары, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының җәмәгать судьялары эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге башлыгы | Хисмәтуллин Наил Нургали улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 22 апрель
№ ПУ-331

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 707. «Татарстан Республикасының Атказанган урманчысы» дигән мактаулы исем бирү турында

Республиканың урман хуҗалыгы тармагын үстерүгә өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының дәүләт урман реестры, урманнардан файдалану һәм урман эшләре комплексы бүлеге башлыгы | Осипов Александр Ивановичка |

«Татарстан Республикасының Атказанган урманчысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 22 апрель
№ ПУ-332

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 708. «Татарстан Республикасының Атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем бирү турында

Мәгариф өлкәсендәге казанышлары һәм намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Казан шәһәре Совет районының «125 нче гимназия» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе директоры | Волобуева Светлана Владимировнага |

«Татарстан Республикасының Атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 22 апрель
№ ПУ-333

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 709. «Татарстан Республикасының Атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем бирү турында

Мәгариф өлкәсендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
